*Гарипова-Хасаншина В. М. (РИИ, Казань)*

# Г. БӘШИРОВ МӘКАЛӘЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИ ӘСӘР ТЕЛЕ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

**Аннотация:** В статье анализируются взгляды классика татарской литературы Г.Баширова на вопросы развития татарского литературного языка. В работе рассматриваются также статьи писателя, посвященные специфике языка художественных текстов, проблемам антропонимии, стилистики, лексикологии татарского языка, лингвистической структуре литературных произведений.

**Ключевые слова:** художественный текст, антропонимика, стилистика, развитие языка, лексический состав языка, билингвизм, калька, проблемы перевода.

**Problems language of literary works in the G. Bashirov's articles**

**Abstract:** The article analyzes the views of classic of Tatar literature G.Bashirov on the development of Tatar literary language. The work analyzes also the article writer on the specifics of the language of literary texts, the problems of anthroponomy, stylistics, lexicology of Tatar language, linguistic structure of literary works.

**Key words:** artistic text, anthroponomy, stylistics, language development, lexical stock of the language, bilingualism, calque, translation problems.

Гомәр Бәширов – XX гасыр әдәбиятының йөзен тудыруда,

халкыбызның рухи-мәдәни тормышында зур урын тоткан шәхес. Әдип өчен тел һәм әдәбият – катлаулы бербөтеннең ике ягы, образлы итеп әйткәндә, ике канаты. Тел берәмлекләренең әдәби әсәр тукымасын төзүдә тоткан урынын яхшы күзаллаган Г.Бәширов: «яхшы әсәр языйм дигән әдип иң элек телен баетырга тырыша. Чөнки... йорт салучыга төзү материалы никадәр кирәк булса, язучыга тел дә шул дәрәҗәдә үк кирәк», – дигән караштa тора [3, Б.306]. Әдипнең язу стилен өйрәнүдә күп хезмәт куйган С.Ш.Поварисов бу уңайдан Г.Бәшировның нәфис сүз остасы булуына, һәр сүз эчендә энҗе барлыгын аңлап язучы икәнлегенә басым ясый, әсәрләре теленең грамматик төзек булуын, камиллеген каткат ассызыклый [7, с.155]. Әлеге фикернең дөреслеген язучының әдәби мирасы гына түгел, ә бәлки күпсанлы тәрҗемәләре, фольклористика, филология өлкәсенә нисбәтле мәкалә-очерклары, хезмәтләре дә раслый. Г.Бәширов әдәби әсәр телен «тотрыклы, ябык, тәмамланган структура» [4, с.131] буларак кабул итә, әсәргә сүз сайлау принципларын ачыкларга омтыла.

Язучы әдәби әсәр теле проблемасын беренче тапкыр 1951 нче елда «Литературная газета»ның 3 нче июнь санында «Язык реализма» мәкаләсендә күтәреп чыга. Сәнгати текстка сүз сайлау процессын реализм методы кысаларында гомуми планда тасвирлаган бу мәкаләсендә автор язу стиле күпләргә үрнәк булырлык әдипләрнең теленә бәя бирә. Монда Г.Бәширов реализм методы белән иҗат итүчеләрнең теле нинди булырга тиешлеген үзенең һәм башка каләмдәшләренең әсәрләрен анализлау аша ачыкларга тырыша, әдәби әсәр теленең баю чыганаклары хакында уйлана. Мисал өчен, бу уңайдан автор: «Каюм Насыйри кулы белән язып алынган татар халык экиятләрендә халык теленең сафлыгына сокланасың, телнең көченә ышанып, кадерен, урынын белеп кулланганда иң гади сүзләргә дә җан өрергә мөмкин», – дип яза.

1952-1960 нчы елларда Г.Бәширов «Совет әдәбияты» журналы белән актив хәбәрләшеп тора. Шуның нәтиҗәсе буларак, бу чорда әдипнең татар әдәби теленең актуаль мәсьәләләрен чагылдырган мәкаләләре бер-бер артлы дөнья күрә: «Тел турында кайбер фикерләр» (1952, №7), «Бер сүз турында берничә сүз» (1963, №3), «Тагын берничә сүз» (1963, №5), «Бай булсын, матур булсын» (1963, №7). Шулай ук автор «Азат хатын», «Социалистик Татарстан», «Литературная газета»

битләрендә дә чыгыш ясый: «Обогащать родной язык» («Литература и жизнь», 1960, 6 нчы май), «Балагызга матур исем» (Азат хатын», 1972, №7) «Тел – тормышның көзгесе» («Социалистик Татарстан», 1973, 27 нче май). Г.Бәширов, әлеге мәкаләләрен туплап, «Бүген дә, иртәгә дә» (1974) дип исемләнгән җыентык чыгара.

1950-60 һәм 70 нче еллар башына нисбәтле язмаларында Г.Бәширов, тел һәм сөйләм күренешен лингвистик, стилистик һәм поэтик системалар бергәлегендә анализлый, телнең статик һәм функциональ халәтенең үзенчәлекләре, телнең «эчке резервлары» [1, с.236] хакында фикер йөртә. Шулай ук әдәби әсәр тукымасын төзүдә аерым тел берәмлекләренең вазифасы, әдәби әсәр тудыру процессында сүз сайлау, татар әдәби теле лексикасында барган уңай һәм тискәре күренешләр хакында сүз алып бара.

1970-80 нче елларда да Г.Бәширов әлеге проблеманы күзәтүләрен, тикшерүэзләнүләрен дәвам итә. Язмаларыннан аңлашылганча, тәҗрибәсе арткан, гомер йомгагы сүтелә барган саен, язучы үзенә дә, башкаларга да таләпчәнрәк була бара. Автор татар әдәби теле һәм, гомумән, тел өлкәсендә барган өзлексез хәрәкәтне лингвистик кына түгел, ә бәлки җәмгыяви-тарихи, иҗтимагый-сәяси, менталь, фәлсәфи-эстетик, ягъни экстралингвистик факторлар яссылыгында да анализларга омтыла, тел һәм фикерләү системасының закончалыкларын, үзара мөнәсәбәтен әдәби һәм сөйләмә тел материалында тикшерә. Шулар тәэсирендә «Дөрес яза беләбезме икән?», «Бай булсын, матур булсын», «Тел күрке – сүз», «Үз өеңдә бар чагында читкә әҗәткә чыкмыйлар», «Гүзәл фәкать үз урынында гына гүзәл», «Сүзләр модасы», «Тел – эстетик тәрбия чарасы», «Исем һәм җисем», «Телнең сафлыгын сакларга», «Хатлар укыганда» һ.б. мәкаләләре языла. Аларда бүгенге көн өчен дә актуаль булган берничә юнәлешне күрсәтергә мөмкин:

-татар әдәби теле һәм аның үсеш-үзгәреше;

-бу процесста әдипләрнең тоткан урыны, иҗат стилен тудыручы чаралар;

-әдәби әсәр теленең лексик составы, аны баету юллары, сәнгати текст эчендә сүз;

-татар әдәби телен өйрәнү, билингвизм шартларында телнең үсеш процессы һәм төп тенденцияләре;

-сөйләм теле һәм әдәби телнең үзара тәэсир итешүе, бу күренешнең матур әдәбиятта чагылышы;

-аерым тел берәмлекләренең әсәр тукымасында тоткан уры-

ны, аерым сөйләм берәмлеге буларак үзенчәлеге;

-поэтик ономастика мәсьәләләре.

Болардан аңлашылганча, автор каләменең колачы зур, амплитудасы киң. Әмма Г.Бәшировның тел өлкәсенә нисбәтле хезмәтләре белән танышу, анализлау барышында шунысын да истә тоту мөһим: аларның авторы тел белгече дә, галим дә түгел. Әлеге язмаларга бу күзлектән чыгып бәя бирү үзен аклап бетермәс кебек. Безгә калса, бу мәкаләләр, иң беренче чиратта, гомере буена нәкъ менә сүз белән эш иткән, татар теленең чиксез зур лексик хәзинәсен язма сөйләмдә файдалану остасына әверелгән шәхеснең тәҗрибәсе, практик эшчәнлеге нәтиҗәсендә туган уй-фикерләре җәһәтеннән кадерле булырга тиеш. Бу мәкалә-очеркларда иҗат итү процессында сүз сайлауның четерекле, авыр яклары да, каләм әһеленең телгә мөнәсәбәте, аны ни дәрәҗәдә аңлавы, кабул итүе, психологик кичерешләре дә урын алган, алар шуның белән әһәмиятле дә. Әлеге язмалар, иң элек, Г.Бәшировның үзе хакында уйланулары, «иҗатының йошак яклары-на билгеле бер анализ ясаган сыман, аны күз алдына китереп, шуларны кәгазь өстенә төшерүе» [1, с.228].

Тел – бертуктаусыз үсеп-үзгәреп торучы хәрәкәттәге организм. Әдәби телнең һәрчак үсеп-үзгәреп торучы катлаулы система икәнен аңлаган хәлдә, автор түбәндәге әһәмиятле моментка басым ясый: «әдәби тел халыкның тарихи, иҗтимагый үсеше тәэсирендә йөз еллар буенча үзгәрә, камилләшә, байый барса да, тормыш таләп иткән яңалыкларны фәкать үз кануннары, үз кагыйдәләре сыйдырган микъдарда, һичшиксез зарури булган тәкъдирдә генә кабул итә» [1, с.262]. Г.Бәширов билгеләп үткәнчә, «телнең бу җәһәттән үз яшәеш юлы, үз холкы бар» дияргә мөмкин [1, с.262-263]. Әдип телнең бернәрсә дә, шулай ук чит факторлар да җимерә алмаслык эчке, потенциаль үсеш кануннары булуына ышана. Әдәби телнең сүзлек составы баю, үзгәрү чыганаклары итеп язучы берничә факторны атый:

- әдәби тел тормышта урын алган яңа вакыйгалар белән килеп кергән яңа сүзләр хисабына тулылана;

- «әдәби телебез, яңа сүзләрдән тыш, терелеп кайткан элекке сүзләр хисабына» да байый. Моңа мисал итеп, автор бәян итү, рухи халәт, битараф кебек сүзләрне китерә.

Г.Бәширов мондый берәмлекләрне «тузан баскан китап шүрлекләреннән төшеп, хәзерге заман кешеләренә хезмәт итә башлаган кирәкле

сүзләр» [1, с. 267] буларак бәяли. Язучы карашынча, алар әдәби телнең тасвир көчен арттыралар, мәгънә нечкәлекләрен төрле нюансларда тулырак итеп бирергә мөмкинлек тудыралар. Шулай да «һәр нәрсәнең үз урыны һәм чамасы бар» [1, с.2 67-268], бу аеруча әдәби әсәр телендә ачык күренә. «Әгәр дә элекке зыялылар хакында сүз барганда, персонаж сөйләме буларак «канәгать хасил кыйлды» яки «фәләннең халәте рухиясе» дип языла икән, бу бик табигый. Чөнки ул заман укымышлыларының теле шулай булган [1, с. 68]. Ләкин бу хәзерге көн әдәби әсәрләрнең теле мондый формалар белән чуарланырга тиеш, дигән сүз түгел, әлбәттә. Шул рәвешчә, Г.Бәширов телдә искергән сүзләрнең кире кайту тенденциясенең әдәби әсәрдә чагылыш үзенчәлеген билгеләргә омтыла, әсәрдә сурәтләнгән дәвер һәм аны укучыга җиткергән лексиканың үзара мөнәсәбәтен тикшерә, критерийларын билгели.

«Әдәби тел үзенең үсешендә, табигате буенча бик тә сизгер тере организмга охшый» [3, с.161]. Бу организм язучы билгеләвенчә, лексикада сүзләрнең төшеп калуына да, яңа сүзләр барлыкка килүнең бер юлы – калькалаштыруга да, чит телләрдән сүзләр кабул итү мәсьәләсенә дә битараф калмый. Шунысын да искәртергә кирәк: автор лексик кына түгел, ә морфологик, синтаксик, стилистик дәрәҗәдә бара торган калькалаштыру хакында да фикер йөртә.

Чит телләрдән сүзләр кабул итү мәсьәләсенә әдипнең үз катгый карашы бар. Г.Бәширов укучының, замандашының игътибарын бер нәрсәгә юнәлтә: «башка телләрдән нинди генә рәвештә файдаланган сурәттә дә, һәр телнең һич тә бозарга ярамый торган катгый һәм мәҗбури бер кагыйдәсе бар. Ул да булса, чит телдән кергән сүзләр шушы тел кагыйдәләренә буйсынып, безнеңчә әйтелергә, безнеңчә язылырга тиеш [3, с. 164]. Телебездәге барлык алынма лексик берәмлекләрнең дә безнеңчә язылуы һәм әйтелүе мөмкин түгел, әлбәттә. Алар арасында дөньяда киң таралыш алганнары һәм барлык илләр өчен дә бердәй яңгыраганнары бар.

Тәрҗемә өлкәсендә тәҗрибәсе шактый булган Г.Бәширов фикеренчә, «әгәр инде чит телдән бөтен бер җөмлә, мәкаль-әйтем, афоризм кебекләр алына икән, андыйларны кайберәүләр әйтмешенчә, «бер тиенгә – бер тиен «, ягъни сүзгә-сүз тәрҗемә итү генә җитми. Андыйларга нәкъ шул мәгънәне аңлатырдай, шул образны

бирердәй тел чараларын туган телнең үзеннән табарга кирәк була. Ләкин кызганычка каршы, «нечкә җиреннән өзелә» дигәндәй, мәгънәсез сүзләр, җансыз җөмләләр нәкъ менә шушы «тар» урында күбрәк кабатлана да инде» [3, с.172]. Автор, күргәнебезчә, татар әдәби теле лексикасында киң дулкын булып җәелгән бу күренешнең телне баету белән бергә, бай традицияле милли тел буларак яшәүдән туктатырга мөмкин икәнлегенә кат-кат басым ясый, үзенең борчылуын да яшерми. Бу нисбәттән, әдип: «матбугатта һәм сөйләмдә тел бозу, телнең бай хәзинәсеннән файдаланмыйча, үзең иҗат итмичә, «әйдә, ярар әле» дигәндәй, әзер шаблоннар, калькалар беләнрәк эш итү ул әле техник җитешсезлек кенә түгел», ә бәлки үзең эш иткән тел материалының табигатен аңламау, – дип яза [3, с.174].

Әдип мондый тел бозулар күпкә китсә, алар газета-журналларда басылган яки радиода сөйләнә торган бик кирәкле материалның да кадерен бетерә, тәэсир көчен юкка чыгара, күңелдә канәгатьсезлек хисе туа башлый, дигән караштa тора. «Беренче карашка, калькаларның телгә әллә ни зыяны юк кебек. Әмма бу ялгыш фикер. Урынлы-урынсыз ясалган, кулланылган морфологик, лексик, синтаксик калькалар телне эчтән кимерүче» [3, с. 82], бозучы куркыныч көч булып торалар. Г.Бәширов фикеренчә, иң әһәмиятлесе һәм аянычы шунда: бу әйберне язган кеше татарча язам дип яза, сөйләүче дә татарча сөйлим дип сөйли. Г.Бәширов сүзләрен раслау максатыннан, «ул үз акылындагы кеше – он в своем уме (югыйсә шул ук фикерне саф татар телендә аның үз акылы үзенә җиткән дип, яисә үз акылы үзендә дип әйтергә мөмкин булыр иде); сугышта башын салды – сугышта яраланып кайтты» мисалларын китерә. «Мондый төр ясалмалылык телгә гаҗәеп зур тизлек белән үтеп керергә сәләтле, шуңа да ул куркыныч. Телнең үз чаралары белән үк телнең камиллегенә һәм нәфислегенә зыян сала. Бу күренешнең сәбәбе телнең эчке кануннары белән исәпләшмәүдән килә» [3, с.101]. 80 нче елларда ук әйтелгән бу фикер хәзер иң актуаль, үзәк проблемаларның берсе булып тора [8, Б.5]. Шунысын да әйтик, Г.Бәширов иҗаты бу нисбәттән караганда, чын мәгънәсендә үрнәк, «әдипнең иҗатын өйрәнү чит, чүп сүзләрдән арынырга ярдәм итә» [6, с. 14].

Авторның кыскартуларга, ялгызлык исемнәренең кулланылышына, бу уңайдан очраган хаталарга да үз мөнәсәбәте, үз фикере бар. Г.Бәширов

бу мәсьәләнең бик сак якын килүне таләп итә торган өлкә булуын искәртә. Әдип карашынча, елга, авыл күл, урманнарга кушылган ялгызлык исемнәренең язылышында яки әйтелешендә хата китмәскә тиешле, чөнки андый исемнәр мәңгелек паспорт урынында йөри.. «Моның билгеле бер иҗтимагый-тарихи сәбәпләре дә бар. Ялгызлык исемнәре бик борынгы тарихи кәгазьләрдә, дәүләт күләмендә әһәмиятле булган төрле рәсми документларда теркәлгән, дәүләт тарафыннан чыгарыла торган географик һ.б. карталарда шул исем белән генә басыла [3, с.111].

Аксакал олпат әдип үзе телгә һәрчак ихтирамлы, игътибарлы, аны нечкә тоеп эш итә. «Телнең халыкның акылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын, мең еллар буена үзенә сеңдерә килеп, безнең заманнарга барып җиткән чиксез хәзинә» [1, Б.270] булуын ассызыклый, «гасырлар караңгылыгыннан бәреп чыкккан бу гаҗәеп чишмәнең гайрәтен индермәскә, аны халыкка тагын да баетыбрак кайтарырга кирәк»леген [1, с. 270] искәртә. Шагыйрь Зөлфәт белән әңгәмәсендә Г.Бәширов шундый сүзләр әйтә: « халкыбыз рухы туган телебез исән булса әдәбиятыбыз зур дигән сүз» [5, с. 150]. Бу фикергә тугрылыгын ул гомере буе саклый, әдипнең милләтенә, теленә зур ихтирам белән сугарылган әсәрләре үзе үк шуңа кире каккысыз дәлил булып тора.

Әдәбият:

1. Бәширов Г. Бүген дә, иртәгә дә/ Г.Бәширов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. – 272 б.
2. Бәширов Г. Әсәрләр. 4 томда. Т.4. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. – 526 б.
3. Бәширов Г. Тормыш юлында / Г.Бәширов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. – 383 б.
4. Виноградов В.В. О языке художественной прозы: Избранные труды/ В.В.Виноградов. – М.: Наука, 1980. – 360 с.
5. Зөлфәт Кадерлебез әдәбият/ Зөлфәт// Гасырлар авазы. – 2001. – №1-2. – 148-151 б.
6. Миңнебаев К. Ана теленең кадерен белик/ К.Миңнебаев // Мәгариф. – 2003. – №5. – 13-14 б.
7. Поварисов С.Ш. Тел – күңелең көзгесе/ С.Ш.Поварисов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – 160 б.
8. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы/ Р.А.Юсупов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2003. – 223 б.